

## Юбилеегыз белән, Фәния Зиннәтовна!

Бүген авылдашыбыз, авылыбызның чын патриоты, күптөрле матур һәм креатив чаралар авторы, район һәм республикада төрле бәйгеләрдә җиңеп авылыбызны биеккә күтәрүче, Бәзәкә авылы сайтының иң актив волонтеры хөрмәтле Фәния Зиннәт кызы Бәшәрованың матур юбилее.

Фәния ханым, барлык авылдашлар, якташлар, сайт укучылыры исеменнән Сезне олы тормыш бәйрәмегез белән котлыйбыз! Алга таба да ачык йөзле, киң күңелле, матур сүзле, тырыш һәм тапкыр булып, гаиләгезнең, балаларыгызның, оныкларыгызның, якыннарыгызның һәм дусларыгызның мәхәббәтенә һәм хөрмәтенә төренеп озак гомер итәргә язсын! Зур рәхмәт Сезгә авылыбыз өчен эшләгән изге гамәлләрегез өчен! Алар барысы да Үзегезгә, гаиләгезгә йөз булып кайтсын!